Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге составына керүче
Мельничный Починок авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

20 ноябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 18 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: “Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең Мельничный Починок, Наратлы авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре), 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы»:
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясе җиһазларын тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;
- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су белән тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 174 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 89 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 89 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлеге составына керүче Мельничный Починок авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип таныйрга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: “Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең Мельничный Починок, Наратлы авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре), 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы»:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясе җиһазларын тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;
- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су белән тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Уракчы авылы, Совет урамы, 36Айорт; Мельничный Починок авылы, Киров урамы, 20Б йорты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Уракчы авыл җирлеге башлыгы: Гәрәев Ф.М